# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Өтәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2023 елның 22 ноябре** **№9**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 22 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Өтәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) юлга вак таш салу;
2) контейнер мәйданчыгы төзү;
3) Тынычлык урамы буенча күчерү торбалары урнаштыру;
4) смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **40** кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә **23** кеше катнашты, бу **57,5%** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда **23** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Өтәк торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге Өтәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2024 елда үзара салым акчасын 1000,00 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) юлга вак таш салу;

2) контейнер мәйданчыклары төзү;

3) юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү;

4) урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту;

5) смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорт (СДК бинасы).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Зеленодольск муниципаль районы
Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы. А.А. Клопов